РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«27» февраль 2024г.

№ 30

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 453 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенең 2024 елның 16 гыйнварындагы № ЭВ-09-25/3433 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 453 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» карарына (24.02.2014 № 86, 23.05.2016 № 504, 23.03.2017 № 141, 20.11.2017 № 701, 12.09.2019 № 511, 10.04.2020 № 173, 29.01.2021 № 32, 01.06.2021 № 200 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) әлеге карар белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә:

- 4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында мәгълүмат социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада (алга таба - ЕЦП) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә урнаштырыла.».

- 4.2 пунктны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин